МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.05.2018 Казан ш. № 232

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июнендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының "Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында" 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне расларга.

2. "Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында" 2016 елның 18 мартындагы 72 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **Ф.С. Габделганиев**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
22.05.2018, № 232
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә белән "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июнендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының "Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында" 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясен (алга таба - Комиссия) төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия үзенең эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып башкара.

3. Комиссиянең төп бурычы түбәндәгеләргә ярдәм итүдән гыйбарәт:

а) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре) тарафыннан чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яки җайга салу турында таләпләрнең үтәлешен тәэмин итүдә, шулай ук алар тарафыннан "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән бурычларның үтәлешен тәэмин итүдә (алга таба - хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр);

б) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында (алга таба - Министрлык) коррупцияне кисәтү буенча чаралар башкаруда.

4. Комиссия хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше белән бәйле мәсьәләләрне Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба - дәүләт хезмәте вазыйфалары) биләүче дәүләт граждан

хезмәткәрләренә кагылышлы (вазыйфаларына билгеләү һәм аннан азат итү Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) карый.

5. Вазыйфаларына билгеләү һәм аннан азат итү Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә кагылышлы хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше белән бәйле мәсьәләләр тиешенчә Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше комиссияләре тарафыннан карала.

6. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы икътисад министры тарафыннан (алга таба - Министр) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан билгеләнеп куела торган Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм әгъзалары керә. Карарлар кабул иткәндә Комиссиянең барлык әгъзалары да бертигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда аның бурычларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) министр урынбасары (Комиссия рәисе), коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы йә Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге хезмәткәрләре, юридик бүлек башлыгы, Министрлыкның башка бүлекчәләренең Министр билгели торган хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе вәкиле;

в) эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмаларaы һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

8. Министр Комиссия составына түбәндәгеләрне кертү турында карар кабул итә ала:

а) "Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында" 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22.1 статьясы нигезендә Министрлык каршындагы иҗтимагый совет вәкилен;

б) Министрлык каршындагы Ветераннар советы вәкилен;

в) Министрлыкның беренчел һөнәри оешмасы вәкилен;

9. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы "б" һәм "в" пунктчаларында һәм 8 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе һәм (яки)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе, фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалараы һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, Министрлык каршындагы иҗтимагый совет, Министрлык каршындагы Ветераннар советы, Министрлыкның беренчел һөнәри оешмасы белән килештерелеп, Министр соратуына нигезләнеп кертеләләр. Килештерү сорату алынган көннән алып 10 көн эчендә башкарыла.

10. Комиссиянең Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләмәгән әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми исәбеннән кимендә дүрттән бер өлешен алып торырга тиеш.

11. Комиссия составы Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясарга мөмкин мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималын булдырмаслык итеп төзелә.

12. Комиссия утырышларында киңәшләшү тавышы хокукы белән түбәндәгеләр катнаша:

а) хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә Комиссия тарафыннан карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм әлеге мәсьәлә Комиссия тарафыннан карала торган дәүләт хезмәткәре били торган шундый ук дәүләт хезмәте вазыйфасын Министрлыкта били торган ике дәүләт хезмәткәре, соңгыларын Комиссия рәисе билгели;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын били торган башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм комиссия тарафыннан карала торган башка мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алган белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; мәнфәгатьле оешмалар вәкилләре; хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә Комиссия тарафыннан карала торган дәүләт хезмәткәренең вәкиле - әлеге мәсьәлә Комиссия тарафыннан карала торган дәүләт хезмәткәренең яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының гозернамәсенә нигезләнеп, Комиссия утырышына кимендә өч көн кала билгеле бер һәр очрак буенча аерым кабул ителә торган Комиссия рәисе карары буенча.

13. Комиссия утырышы анда Комиссия әгъзаларының гомуми исәбеннән кимендә өчтән ике өлеше булганда хокукка ия дип санала. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары гына катнашкан утырышлар үткәрү рөхсәт ителми.

14. Комиссия әгъзасында Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин турыдан-туры яки кыек шәхси мәнфәгате барлыкка килгәндә, ул бу хакта утырыш башланганчы хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

15. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезләр:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә үткәрелгән дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, шулай ук дәүләт хезмәткәренең хезмәт

урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең үтәлүен тикшерү йомгаклары буенча Министр тарафыннан тикшерү материалларының тапшырылуы, алар түбәндәгеләрне күрсәтә:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәдә каралган дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөрес булмавын һәм тулы булмавын;

дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлмәвен;

б) Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә йә дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы әйдәүче белгеченә (алга таба - әйдәүче белгеч) Министрлыкның норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә кергән:

Министрлык боерыгы белән расланган Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә аны биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру таләп ителгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфаны биләгән гражданның коммерция яки коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерция яки коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамәсе шартларында эш башкаруга, әгәр әлеге оешмага дәүләт идарәсенең аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына кергән булса, дәүләт хезмәтеннән китү көненнән алып ике ел булганчы рөхсәт бирү турында мөрәҗәгате

хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне объектив сәбәпләр аркасында тапшыра алмавы турында дәүләт хезмәткәре гаризасы;

"Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, нал акчаларны һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүнең территориясендә счетлар (кертемнәр) булган, чит ил банкында нал акчалар саклана торган һәм (яки) чит ил финанс кораллары булган әлеге чит дәүләтнең компетентлы органнары салган кулга алуга, эш итүне тыюга бәйле рәвештә, яки аның ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар аркасында мөкин булмавы турында дәүләт хезмәткәре гаризасы;

вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында дәүләт граждан хезмәткәренең хәбәр итүе;

в) Министрның яки теләсә кайсы Комиссия әгъзасының дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлешен йә Министрлыкта коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә кагылышлы тәкъдим кертүе;

г) дәүләт хезмәткәренең "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килү-килмәвен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган дөрес яки тулы булмаган белешмәләр тапшыруын раслый торган тикшерү материалларының Министр тарафыннан бирелүе;

д) коммерция яки коммерциягә карамаган оешманың Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән хезмәт яки эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) гражданлык-хокук шартнамәсе төзелү турында, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсенең аерым функцияләре Министрлыкта вазыйфа биләгән вакытта башкарыла торган аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына кергән булса, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә Министрлыкка кергән хәбәрнамәсе, тик күрсәтелгән гражданга элек Комиссия әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокук мөнәсәбәтләренә керүдә баш тартылган яки мондый гражданга аның тарафыннан коммерция яки коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерция яки коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокук шартнамәсе шартларында эш башкаруга рөхсәт бирү турындагы мәсьәлә Комиссия тарафыннан каралмаган булса.

16. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасы бозылу фактлары буенча тикшерүләр үткәрми.

16.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә йә әйдәүче белгечкә тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән киткән көненә кадәрге соңгы ике елда биләгән вазыйфалары, коммерция яки коммерциягә карамаган оешманың урнашу урыны, аның эшчәнлеге билгеләре, дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән вакытта граждан башкарган вазыйфа (хезмәт) бурычлары, коммерция яки коммерциягә карамаган оешмага карата дәүләт идарәсе функцияләре, шартнамәнең төре (хезмәт яки гражданлык-хокук), аның гамәлдә булуының фараз срогы, шартнамә буенча башкарылган (күрсәтелгән) эшләр (хезмәтләр) өчен түләү суммасы. Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге йә әйдәүче белгеч мөрәҗәгатьне карый, аның нәтиҗәләре буенча, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25

декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча нигезләнгән бәяләмә әзерләнә.

16.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китүне планлаштыра торган дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелә ала һәм, әлеге Нигезләмәгә таянып, Комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

16.3. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "д" пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге йә Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен үтәве турында нигезләнгән бәяләмә әзерли торган әйдәүче белгеч карый.

16.4. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге йә хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли торган әйдәүче белгеч карый.

16.5. Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге йә әйдәүче белгеч әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге йә хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмәне яки әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының бишенче абзацында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне әзерләгәндә мөрәҗәгать керткән яки хәбәрнамә тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздырырга, аннан язма аңлатмалар алырга хокуклы, ә Министр яки аның махсус вәкаләт бирелгән урынбасары дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьле оешмаларга билгеләнгән тәртиптә соратулар җибәрә ала. Мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки хәбәрнамә кергән көннән алып җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Соратулар җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма иң күбе 30 көнгә.

16.6. Әлеге нигезләмәнең 16.1, 16.3 һәм 16.4пунктларында каралган нигезләнгән бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яки хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) соратулар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм мәнфәгатьле оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яки хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән йомгак, шулай укәлеге Нигезләмәнең 23, 24.3, 25.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яки башка карарлар кабул итү өчен тәкъдимнәр.

17. Комиссия рәисе аңа Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат Министрлыкның норматив хокукый актында каралган тәртиптә кергәндә:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы датасы күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән алып 20 көннән дә соңга калмаска тиеш, моңа әлеге Нигезләмәнең 17.1 һәм 17.2 пунктларында каралган очраклар керми;

б) Комиссия тарафыннан хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше хакында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәрләрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә йә әйдәүче белгечкә кергән мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 12 пунктындагы "б" пунктчасында күрсәтелгән затларны Комиссия утырышына чакыру турында үтенечне карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материаллар карау турында (караудан баш тарту турында) карар кабул итә.

17.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срок беткән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

17.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "д" пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план буенча) утырышында карала.

18. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше хакында мәсьәлә карала торган дәүләт граждан хезмәткәрләре яки Министрлыкта дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән граждан катнашында уздырыла. Дәүләт граждан хезмәткәре яки граждан Комиссия утырышында шәхсән үзенең катнашырга теләге булу турында әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрнамәдә күрсәтә.

18.1. Комиссия утырышы түбәндәге очракта дәүләт граждан хезмәткәре яки граждан булмаганда уздырылырга мөмкин:

а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрнамәдә дәүләт граждан хезмәткәре яки граждан Комиссия утырышында шәхсән үзенең катнашырга теләге булу турында белдермәгән булса;

б) Комиссия утырышында шәхсән үзе катнашырга теләгән һәм аны уздыру вакыты белән урыны турында тиешенчә хәбәр ителгән дәүләт граждан хезмәткәре яки граждан Комиссия утырышына килмәсә.

19. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яки Министрлыкта дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

20. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар аларга Комиссия эше барышында билгеле булган белешмәләрне фаш итәргә хокуксыз.

21. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "а" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә таянып, дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;

б) әлеге пунктның "а" пункчасында аталган Нигезләмәгә таянып, дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес түгел һәм (яки) тулы түгел дип билгеләргә; Бу очракта Комиссия Министрга дәүләт хезмәткәренә карата төгәл билгеле җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

22. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "а" пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәгән, дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән, дип билгеләргә; Бу очракта Комиссия Министрга хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне бозарга ярамауны дәүләт хезмәткәренә җиткерергә йә дәүләт хезмәткәренә карата төгәл билгеле җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

23. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерция оешмасында яки коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерция оешмасында яки коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокук шартнамәсе шартларында, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсенең аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына кергән булса, эш башкарырга рөхсәт бирергә;

б) гражданга коммерция оешмасында яки коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүдә йә коммерция оешмасында яки коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокук шартнамәсе шартларында, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсенең аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына кергән булса, эш башкарырга рөхсәт бирмәскә һәм баш тартуның сәбәпләрен күрсәтергә.

24. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр белешмәләр тапшырмауның сәбәбен объектив һәм җитди дип табарга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр белешмәләр тапшырмауның сәбәбен җитди түгел дип табарга; Бу очракта дәүләт хезмәткәренә Комиссия күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру чараларын күрергә тәкъдим итә.

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмауның сәбәбен объектив түгел дип һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан качу ысулы булып тора, дип табарга; Бу очракта Комиссия Министрга дәүләт хезмәткәренә карата төгәл билгеле җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

24.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "г" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килү-килмәвен тикшереп тору турында" Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрне дөрес һәм тулы, дип табарга.

б) "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килү-килмәвен тикшереп тору турында" Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрне дөрес түгел һәм (яки) тулы түгел, дип табарга. Бу очракта Комиссия Министрга дәүләт хезмәткәренә карата төгәл бер җаваплылык чарасын күрергә һәм (яки) чыгымнарны тикшереп торуны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратурага һәм (яки), компетенцияләренә карап, башка дәүләт органнарына җибәрергә тәкъдим итә.

24.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, нал акчаларны һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган шартларны объектив һәм җитди дип танырга;

б) "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, нал акчаларны һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган шартларны объектив түгел һәм җитди түгел дип танырга; Бу очракта Комиссия Министрга дәүләт хезмәткәренә карата төгәл билгеле җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

24.3. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының биштенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгы юк, дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең вазыйфа бурычларын башкаргандагы шәхси кызыксынулы булуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин, дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) Министрга мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки аның барлыкка килүен булдырмый калу өчен чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән, дип танырга. Бу очракта Комиссия Министрга дәүләт хезмәткәренә карата төгәл билгеле җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

25. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "а","б" ,"г" һәм "д" пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча һәм моңа нигезләр булганда Комиссия әлеге Нигезләмәнең 21 - 24, 24.1 - 24.3 һәм 25.1 пунктчаларында каралганнардан үзгә карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.

25.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "д" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданга кагылышлы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) аңа коммерция оешмасында яки коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерция оешмасында яки коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокук шартнамәсе шартларында, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсенең аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына кергән булса, эш башкарырга рөхсәт бирергә;

б) аның коммерция оешмасында яки коммерциягә карамаган оешмада вазыйфаны хезмәт шартнамәсе шартларында биләү һәм (яки) коммерция оешмасында яки коммерциягә карамаган оешмада эшләр башкару "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен боза, дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Министрга күрсәтелгән шартлар турында прокуратура органнарына һәм мәгълүмат җиткергән органга хәбәр итәргә тәкъдим итә.

26. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "в" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

27. Карарларны үтәү өчен Комиссия Министрлыкның норматив хокукый актлары, Министрның карарлары яки йөкләмәләре проектларын әзерләргә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә Министр каравына тапшырыла.

28. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары, яшерен тавыш биреп (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә), утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә.

29. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга аның утырышында катнашкан Комиссия әгъзалары кул куя. Әлеге Нигезләмәнең 15

пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карарлардан тыш, Комиссия карарлары Министр өчен тәкъдим итү рәвешендә була. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри үтәлергә тиеш.

30. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашкан башка затларның фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре;

б) Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең оештырып язылган рәвеше, анда хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше белән бәйле мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы күрсәтелә;

в) дәүләт хезмәткәренә белдерелә торган дәгъвалар, алар нигезләнгән материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларның асылы буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алган мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның Министрлыкка керү датасы;

ж) башка белешмәләр;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итү нигезләве.

31. Комиссия карары белән килешмәгән аның әгъзасы язма рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул мәҗбүри рәвештә Комиссия утырышы беркетмәсенә беркетелергә һәм дәүләт хезмәткәре аның белән танышып чыгарга тиеш.

32. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш булган көннән алып 7 көн эчендә – Министрга, тулысынча яи аннан өземтә рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча – мәнфәгатьле башка затларга җибәрелә.

33. Министр Комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча карар кабул иткәндә андагы тәкъдимнәрне үз компетенциясе чикләрендә исәпкә алырга хокуклы. Министр Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында Комиссиягә язма рәвештә аңа Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән алып бер ай эчендә хәбәр итә. Министр карары Комиссиянең якындагы утыршында укыла һәм, фикер алышулар үткәрмичә генә, игътибарга алына.

34. Дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (гамәл башкармавында) Комиссия дисциплинар гаеп эш билгеләре булуын ачыкласа, бу хакта мәгълүмат дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган

җаваплылык чараларын күрү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен Министрга тапшырыла.

35. Комиссия дәүләт хезмәткәре тарафыннан административ хокук бозу билгеләре яки җинаять составы булган гамәлләр башкарылу фактын (гамәл башкармау фактын) билгеләгән очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлне башкару (гамәлне башкармау) турында мәгълүматны һәм мондый фактның булуын раслый торган документларны 3 көн эчендә, ә кирәк булганда – кичекмәстән хокук саклау органнарына тапшырырга тиеш.

36. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан өземтә хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турында мәсьәлә каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси делосына теркәп куела.

36.1. Комиссия карарыннан Комиссия секретаре имзасы һәм Министрлык мөһере белән таныкланган өземтә Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга кул куйдыртып тапшырыла яки, тиешле Комиссия утырышы уздырылган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгатьтә үзе күрсәткән адрес буенча тапшырылу хакында хәбәр ителә торган заказлы хат белән җибәрелә.

37. Комиссия эшчәнлегенең оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат тапшыру, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышу өчен бирелә торган материаллар белән таныштыру Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге йә әйдәүче белгеч тарафыннан гамәлгә ашырыла.